СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «10» ноябреннән № 38-307

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән (2022 елның 29 декабрендәге 30-238 номерлы, 2023 елның 16 мартындагы 32-247 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлекнең 14 статьясындагы 6 өлешендә «яисә рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү» сүзләрен «, рекреацион билгеләнештәге зоналарны билгеләү яисә торак пункт чикләренең җир кишәрлекләре чикләре белән кисешүен бетерү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2024 елның 01 февраленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов